## *Юлбатым*

*Нурсанә Рахимуллина сүзләре һәм көе*

Күптәнме соң әле кайткан идем
Өзелеп сагынып сине, Юлбатым.
Менә инде синнән тагын китәм
Сагынырмын сине, Юлбатым.

Кала Казкаш шаулы суы белән,
Карачтау да кала моңаеп.
Мин яраткан каенлыклар кала,
Кала бар да, кала Юлбатым.

Сандугачлар да моңлы сайрый
Юлбатымның яшел талында.
Болыннарга чыгып эзләп йөрим,
Әй, яшьлегем, калдың кайларда?!

Кала иген басулары
Китмә, дигән кебек, Юлбатым.
Сагынсам да китәм, нихәл итим, –
Тормыш шулай куша, Юлбатым.



